Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге
Төрнәс авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«20» ноябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Төрнәс торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм таш җәю;

2.Төрнәс авылында урам утларын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;

3.Төрнәс авылындагы юлларны сезонлы карап тоту;

4.Төрнәстә су белән тәэмин итү чыганакларын норматив хәлгә китерү

(янгын гидрантлары өчен коелар, скважиналарны лицензияләү).

Тагылмалы янгын сүндерү су сыешлыгын сатып алу;

6. Бакча, Мәктәп, Үзәк урамнарын төзекләндерү.

Халык җыенында рәислек итүче: С.В. Белов

Төрнәс авыл җирлеге башлыгы С.В.Белов